**Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең тышкы кыяфәтенә таләпләр**

1. Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 23 мартындагы УП-142 санлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышы һәм этика Кодексының 30 пункты нигезендә, дәүләт гражданлык хезмәткәре, үзенең вазыйфаи бурычларын үтәгән вакыттагы тышкы кыяфәте, хезмәт шартларына һәм хезмәт чараларына бәйсез рәвештә, гражданнарның дәүләт органнарына ихтирамлы мөнәсәбәтен булдыруга булышлык итәргә, рәсмилек, сабырлык, пөхтәлек кебек гомуми кабул ителгән эшлекле стильгә туры килергә тиеш.

2. Тышкы кыяфәт формалаштырганда, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре таянырга тиешле төп кагыйдә булып киемдә эшлекле стильне саклау тора. Төп элементлар түбәндәгеләр:

2.1. ир-атларның тышкы кыяфәтенә таләпләр:

– эшлекле классик костюм, классик күлмәк һәм галстук;

– җәйге вакытта кыска җиңле күлмәктән, ә 25С° температурадан югары булганда пиджаксыз йөрергә мөмкин;

– чалбар классик, стандарт озынлыкта;

– костюмга туры килгән галстук;

– оекбашларның төсе чалбар төсеннән бер тонга караңгырак;

– ботинкалар һәм туфлиләр классик стильдә.

Тәкъдим ителә:

– рәсми хәлләрдә (рәсми чараларда, киңәшмәләрдә чыгыш ясаганда, президиумда булганда һәм башкаларда) пиджакны эләктерергә;

– парфюмерияне чамасын белеп куллану.

Рөхсәт ителми:

– джинс кием-салым;

– спорт һәм пляж аяк киеме;

– шапшак, пөхтә булмаган кием-салым;

– рәсми чараларда кардиганнар, пуловерлар һәм жилетлар киеп йөрү;

(киңәшмәләрдә чыгыш ясаганда, президиумда булганда һәм башкаларда).

2.2. Хатын-кызларның тышкы кыяфәтенә таләпләр:

– тыйнаграк төсләрдәге классик эшлекле костюм;

– пастель тонындагы блузалар. Артык ачык, контраст төстә булмаган рәсемле. Җиң озынлыгы – теләсә нинди, шул ук вакытта иңбаш ябык булырга тиеш;

– блуза белән туры килерлек пуловер, кардиган, классик жилет кияргә мөмкин;

– тыйнак дизайнлы һәм тыйнак төстәге итәк. 15 сантиметрдан артмаган уемы булу рөхсәт ителә.

Озынлыгы: тездән 5-8 сантиметрдан артмаган һәм балтырның яртысыннан да озын булмаган;

– тыйнак төсләрдәге, уртача яки озын җиңле жакет яки пиджак белән классик фасондагы күлмәк;

– туры классик чалбар;

– классик дизайнлы, ябык башлы аяк киеме: туфли, ярымботинкалар.

Уртача үлчәмдәге үкчә – 7-8 сантиметрдан артмаган. Җәйге вакытта ачыграк аяк киеме рөхсәт ителә, ләкин ул аяк йөзенең күп өлешен каплап торырга тиеш;

– колготкаларның төсе киемгә туры килергә, бертөрле тондарак булырга тиеш, ажурлы түгел: тән төсендә, кара, күк, көрән төсләрдә;

– макияж күзгә ташланып тормаска, табигый төсмерләрдә булырга тиеш, пөхтә прическа, уртача озынлыктагы тырнаклар, пөхтә, классик маникюр;

– бизәнү әйберләре: артык күзгә ташланып тормаган аксессуарлар һәм бижутерия.

Тәкъдим ителә:

– парфюмерияне чама белеп куллану.

Рөхсәт ителми:

– джинс кием;

– артык тар, кыска итәкләр һәм тирән уемтыклы итәкләр;

– үтә күренмәле кием;

– блузка һәм күлмәкләрдә тирән декольте;

– итәк һәм күлмәкләрнең максималь озынлыгы (балтыр уртасыннан озынрак);

– нечкә бретелькалардагы топлар, иңбашны капламый торган блузалар

– шапшак һәм пөхтә булмаган кием;

– арка өлеше ачык һәм биле артык түбән кием;

– шортылар, итәк-чалбар, кыскартылган модельле чалбар;

– спорт һәм пляж аяк киеме;

– ачык бизәнү әйберләре, күп сандагы бижутерия;

– ачык, күзгә ташланып торган макияж, тырнаклар өчен артык ачык төстәге лак.

2.3. Ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә ирекләрәк стильдәге кием рөхсәт ителә: ирекле төрдәге чалбар, итәк, куе төсләрдәге свитерлар, джемперлар, классик төстәге һәм тыйнак дизайнлы кием.

Әлеге кагыйдә планлаштырылган чаралар, киңәшмәләр очрагында кулланылмый.